Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе 2нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе” МГББУ укытучысы Токранова Эльвира Ильяс кызының педагогик эшчәнлегенә
бәяләмә.

Токранова Эльвира Ильяс кызы- районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында нәтиҗәле эшчәнлеге белән үз урынын билгеләгән укытучы.

Ул- үз фәнен югары дәрәҗәдә укучыларына җиткерә алучы тәҗрибәле педагог. Аның укучылары фән буенча яхшы белем күрсәткечләренә ия, 2013-14 уку елында тапшырылган ТДИ нәтиҗәләре буенча ул укыткан сыйныфларда сыйфатлы өлгереш 81,4% тәшкил итте.

Укытучы укучылар белән сыйныфтан тыш эшчәнлеккә зур игътибар бирә. Ел саен укучылар белән фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша, призлы урыннар ала. Бу юнәлештә соңгы елларда ирешкән нәтиҗәләре түбәндәге:
- “Татар лингвокультурологиясе: проблемалар и перспективалар "дигән укучылар, студентлар һәм аспирантларның V нче Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә 1 урын (Әхмәтвәлиева А, 11кл.);
- Г.Ибраһимов исемендәге VI нчы республика фәнни-гамәли конференциясендә 3 урын (Һашимова Л., 9кл);
- Т.Миңнуллин исемендәге VI нчы республика фәнни-гамәли конференциясендә 1 урын (Галиева Г. 11 кл);

Муниципаль һәм республика күләмендә фән буенча олимпиадаларда Токранова Э.И. укучылары уңышлы катнаша. Соңгы 3 елда аның укучылары муниципаль этапта 9 урын алды, республика олимпиадасында 4 мәртәбә катнаштылар, 11 нче сыйныф укучысы Галиева Гөлчәчәк 2013-14 нчеуку елында татар әдәбиятыннан республика олимпиадасында призер булды. КФУ олимпиадалары, Халыкара олимпиада, Татартелеинфо, “Зирәк тиен” кебек олимпиадаларда да укучылары даими катнашалар. Район күләмендә үткәрелгән “Татар кызы” конкурсында аның укучысы Әхмәтвәлиева А. 1нче урынга лаек булды.

Эльвира Ильяс кызы үзенең методик тәҗрибәсе белән мәктәп, район һәм республика күләмендә уртаклаша: ачык дәресләр күрсәтә, семинар һәм киңәшмәләрдә, һөнәри бәйгеләрдә чыгышлар ясый, район күләмендә иҗади эшләр һәм олимпиада комиссияләре составында эшли. Ул “Ел укытучысы”Бөтенроссия бәйгесенең муниципаль этабында 2010, 2015нче елларда җиңүче булды, 2011нче елда республика бәйгесендә лаеклы чыгыш ясады.

Укытучы мәктәп базасында алып барыла торган инновацион мәйданчык эшчәнлеге төркеме составында эш алып бара. Эш тәҗрибәсе үрнәкләрен республика һәм регионара конференцияләр эшчәнлеген яктырткан җыентыкларда күрергә була. Мәсәлән, “Диалог культур. Формирование российской гражданской идентичности подрастающего поколения” Төмән шәһәрендә 2015 елда чыккан регионара фәнни-гамәли конференция материаллары арасында “Татар әдәбиятында суфичылык” дигән дәрес эшкәртмәсе; 2015 елда чыккан “Мәшһүр мәгърифәтче- галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану” җыентыгында “Р. Фәхретдинов әсәрләре аша тәрбияви максатка ирешү” дигән мәкаләсе бар.

Укытучы укытучылар каршында да, фәнни-гамәли конференцияләрдә дә актив чыгышлар ясый, тәҗрибәсе белән даими уртаклаша. Мәсәлән, 2016нчы елда Т.Миңнуллин ис. 3нче республика конференциясендә катнашты, Чистай шәһәрендә үткән “Современные

образование: новые требования, новые возможности»  конференциясендә призер исеменә лаек булды. КФУ үткәргән “Татарское языкознание в контексте Евразийской гуманитарной науки” фәнни-гамәли конференциясендә катнашты.

2014нче елда, лаеклы рәвештә, “Безнең иң яхшы укытучыбыз” республика грантына ия булды.

2016 нчы елда Токранова Э.И. БРТ тикшерү комиссиясендә эксперт буларак эшләде.

Токранова Э.И. 2003, 2010 нчы елларда Татарстан Республикасы МҺФМ мактау грамотасы, 2010, 2016нчы елларда Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы мактау хаты, 2015нче елда “Ак калфак” татар хатын кызлары оешмасының Балык Бистәсе муниципаль районы бүлекчәсеннән рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының “Мәгариф
бүлеге муниципаль казна
учреждениесы” башлыгы: И.М. Садыйков

МКУ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»
ОГРН 1121677000087
ИНН 1634008185